**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ МОРДОВСКО-
АФОНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул.,
19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы,
19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru:

**№3** **29.01.2021ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 6424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 26 июнендщге 9 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

ТР Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе
авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе: А.И.Митяев

1нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
29 гыйнвар 2021 ел, № 3

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
бәясе
2021 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2337,72 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1070,85 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3016,41 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

2нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
Башкарма комитеты
карарына
29 гыйнвар 2021 ел, № 3

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
бәясе
2021 елның 1 февраленнән

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 243,50 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2094,22 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1070,85 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3016,41 |
| **БАРЛЫГЫ** | **6424,98** |